**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Манзарас авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**3 ноябрь 2021 ел** **№96**

**«Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Кул авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2021 елның 17 ноябренә 10сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Манзарас авыл җирлегенең Киндер Кул авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Халык җыенын Киндер Күл авылы, Клуб урамы, 20 б адресы буенча урнашкан мәчет бинасында үткәрергә.

2 Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, I төркем инвалидлары, 18 яшькә кадәрге 3 яки күбрәк баласы булган күп балалы гаиләләр яисә ялгыз аналар, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге затлардан кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Киндер Кул авыл җирлегенең Киндер Күл авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 1000 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Киндер Күл авылы зиратын киртәләү, смета документлары;
- Киндер Күл авылында урам юл челтәрен карап тоту(ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү), проект-смета документлары;
- Киндер Күл авылында энергия саклаучы лампаларны, яктырткычларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау, проект-смета документлары, техник күзәтчелек;
- Киндер Күл авылы территориясен төзекләндерү;
- Киндер Күл авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек үткәрү, экспертиза үткәрү;
- Насослар сатып алу һәм урнаштыру;
- Юлларга вак таш җәю, Энергетиклар, Новая урамы, Насыйбуллин урамы, Киндер Күл авылы буенча торбалар сатып алу һәм җәю; (сатып алу, ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү), проект-смета документациясе һәм техник күзәтчелек;
- Киндер Күл авылында янгын гидрантын сатып алу һәм урнаштыру, смета документлары;

«РИЗА» «КАРШЫ»

3. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында һәм җирлекнең рәсми сайтында урнаштыру юлы белән кабул ителгән көннән 5 көн эчендә халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Манзарас авыл җирлеге башлыгы Р. Г. Хәбибуллина